| | |
|---|---|
| **СОВЕТ<br>БАГАЕВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>БАГАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**16.09. 2019 ел** **№ 18**

**Багай авылы**

**Багай авыл җирлегендә җирле<br>референдум үткәрү инициативасы турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131 нче Федераль законның 56 нчы маддәсе, «Россия Федерациясе гражданнарының төп сайлау хокуклары гарантияләре һәм референдумда катнашу хокукы турында»гы 2002 елның 12 июнендәге 67 нче Федераль законның 15 нче маддәсе, Татарстан Республикасының «Җирле референдум турында»гы 2004 елның елның 25 мартындагы 23 нче законынның 12 нче маддәсе, «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Багай авыл җирлеге» муниципаль берәмлек Уставының 11 нче маддәсе нигезендә Багай авыл җирлеге Советы **КАРАР** кабул итте:

1. Багай авыл җирлеге башкарма комитеты белән берлектә Багай авыл җирлегендә референдум үткәрү турындагы инициативаны түбәндәге сорауларны кертеп үткәрергә:

«Сез, 2020 елда Багай авыл җирлегендә 18 яше тулып, референдумда катнашу хокукы булган һәр кешедән үзара салым акчасының бер тапкыр 500 (биш йөз) сум күләмендә түләнүе белән килешәсезме». Үзара салымнан кергән керем түбәндәге юнәлешләрдә тотыла:

*а) авыл җирлеге территориясен төзекләнләндерү:*

- урамнардагы яктырткычларны ремонтлау, моның өчен материаллар сатып алу;

-балалар мәйданчыкларын төзекләндерү һәм моның өчен материаллар сатып алу;

-парк тирәсен тытып алу һәм моның өчен материаллар сатып алу;

*б) авыл җирлеге чикләрендәге халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:*

-суүткәргеч челтәрен ремонтлау һәм моның өчен материаллар сатып алу;

*в) авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек:*

- юлларны норматив хәлгә китерү, моның өчен материаллар сатып алу;

- авыл җирлеге чикләрендәге автомобиль юлларын карап тору;

*г) ритуаль хезмәт күрсәтүне оештыру, җирләү урыннарын тиешле тәртиптә тоту:*

- зиратларны чистарту һәм җирләү урыннарын тиешле тәртиптә тоту.

2. Әлеге карарны мәгълүмати стендларга һәм авыл җирлегенең рәсми сайтына веб-адреска: http://bagaev-kaybici.tatarstan.ru. урнаштырырга.

3. Карар рәсми рәвештә халыкка җиткерелгәннән соң үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Багай авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Багай авыл җирлеге башлыгы** **Р.Ф.Кузнецова**